ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutazaik@mail.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«** 19 **»** 12 **2023г.** **№**2185

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының «Янгыннан саклау буенча социаль юнәлешле иҗтимагый берләшмәләргә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2012 елның 31 гыйнварындагы 78 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Ирекле янгын сагы турында» 2011 елның 06 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Янгыннан саклау буенча социаль юнәлешле иҗтимагый берләшмәләргә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының 2012 елның 31 гыйнварындагы 78 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пункты 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ирекле янгын сүндерүчеләрне һәм ирекле янгын сагы иҗтимагый берләшмәләрен, ирекле янгын сагы хезмәткәрләрен әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү өлкәсендә ярдәм итүне;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга .

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина